**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 18 апрелендәге 1242 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы 247 номерлы «“2022-2024 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә, программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарны төгәлләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы 247 номерлы «“2022-2024 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 4 маендагы 1264 номерлы, 2024 елның 27 апрелендәге 1669 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. программа паспортында «Программаны елларга һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

<table>
<tr><td>«Программаны елларга һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләме</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 184 685,2 мең сум тәшкил итә.

<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Барлыгы</th><th>Казан шәһәре муниципаль бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2022</td><td>55 483,8</td><td>55 483,8</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>62 849,0</td><td>62 849,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>66 352,4</td><td>66 352,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>184 685,2</td><td>184 685,2</td><td>-</td></tr>
</table>

Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»</td></tr>
</table>

1.2. III бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү**

Программа Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына финанслана. Финанслауның гомуми күләме 184 685,2 мең сум тәшкил итә:

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| 2022 | 55 483,8 | 55 483,8 | - |
| 2023 | 62 849,0 | 62 849,0 | - |
| 2024 | 66 352,4 | 66 352,4 | - |
| **БАРЛЫГЫ** | **184 685,2** | **184 685,2** | **-** |

Финанслау күләме фаразлау рәвешендә бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин»;

1.3. программаның кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.4. Әлеге карарның кушымтасын программаның кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 18 апрелендәге
1242 номерлы карарына
кушымта

**Программаның максаты, бурычлары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау**

| Бурычның атамасы | Төп чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Чыганагы күрсәтелгән финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 база елы | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максат: төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу очракларын профилактикалау, кисәтү, ачыклау һәм булдырмау | | | | | | | | | | | |
| 1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру | Планнан тыш контроль чаралар үткәрү | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 еллар | Суд тәртибендә дәгъваланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозуларны төзәтү турында күрсәтмәләр саны | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| 2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту | Физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кылынган административ хокук бозуларны кисәтү, | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль | 2022-2024 еллар | Казан шәһәрен төзекләндерү өлкәсендә гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча һәм муниципаль норматив хокукый актларның | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| Бурычның атамасы | Төп чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Чыганагы күрсәтелгән финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 база елы | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| | ачыклау һәм булдырмау | казна учреждениесе | | мәҗбүри таләпләрен бозуларның ачыкланган һәм алар буенча чаралар күрелгән өлеше % | | | | | | | |
| 3. Үз вәкаләтләрен башкару буенча идарә эшчәнлеген тәэмин итү | Хезмәткәрләрне һөнәри яктан укыту | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2022-2024 еллар | Өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча квалификация күтәрү үткән хезмәткәрләр саны | 23 | 20 | 15 | 15 | | | |
| **Программа буенча БАРЛЫГЫ – 184 685,2 мең сум** | | | | | | | | | **55 483,8** | **62 849,0** | **66 352,4** |